# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИАЛЬ САЙЛАУ КОМИССИЯСЕ

# К А Р А Р

19.11.2018 №207

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендәге җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, участок комиссияләренең тавыш бирү нәтиҗәләре турында участок комиссияләренең беренче нөсхәләре мәгълүматлары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе 2018 елның 19 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзегән, аның нигезендә, 2018 елның 18 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде:

Референдумда катнашучылар исемлегенә тавыш бирү тәмамлануга 891 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны-763, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлегенә кертелгән референдумда катнашучыларның 85,63% ын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен референдумда катнашкан 613 (80,34%) кеше тавыш бирде, бу тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның 50 проценттан артыгын тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашкан 150 кеше тавыш бирде, бу19,66% тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының территориаль сайлау комиссиясе карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә **2018 елның 18 ноябрендәге җирле референдум** узган, референдум нәтиҗәләре - гамәлдә дип танырга.

2. "2019 елда, Яңа Кишет авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә (түләү күләме 250 сум тәшкил иткән укуның көндезге формасында укучы студентлардан тыш) үзара салым акчасын җыярга һәм аны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү белән килешәсезме?

1. Авыл җирлегенең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-Яңа Кишет авылында: Тынычлык, Дуслык урамнарын; Иске Кишет авылы: Күпер, Дуслык, г. Сафиуллин урамнарын; Кшкар авылы Тынычлык урамын; Симетбаш авылы: Узәк урам.

2. Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән Яңа Кишет, Иске Кишет, Кшкар, Симетбаш авылларында яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, счетчиклар, автоматлар, җибәргечләр сатып алу һәм урнаштыру;

-бензинлы чапкыч- 2 данә;

3. Торак пунктлар чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү:

- Кшкар -2шт, Симетбаш - 1шт авылларында янгын гидрантлары сатып алу һәм урнаштыру.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта акчаны Яңа Кишет авыл җирлеге Башкарма комитетына референдумда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә рөхсәт итәргә" дигән мәсьәлә буенча карар кабул ителде дип танырга.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Арча хәбәрләре» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кишет авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе — Б. И. Кадыйров

Татарстан Республикасы Арча районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре — Л. И. Нурмиева